# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 13 ноябрендә «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Кече Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Кече Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Кече Әтрәч авылында Тукай ур., Советская ур. Юлларны төзекләндерү;
- Кече Әтрәч авылы зираты территориясен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 167 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 93 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 93 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Зур Әтрәч авыл җирлегенең Кече Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Кече Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Кече Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Кече Әтрәч авылында Тукай ур., Советская ур. Юлларны төзекләндерү;
- Кече Әтрәч авылы зираты территориясен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **И.Ш. Юнусов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы** **И.Ш. Юнусов**